әләген, Бөек һәм көчле телне   Татарстан мәктәпләрендә   килешер дип уйлыйм. Ә   үстем һәм гадәти булмаган   телебезне,   халкыбызны   әгъзасы.

# Халкыбызның тарихын өйрәнәбез

**Шушы көннәрдә генә Ульяновскиның 17 нче санлы милли китапханәсендә ислам динен һәм халкыбыз тарихын киң җәмәгатьчелеккә җиткерү максатында зур көч һәм тырышлык куючы милләтпәрвәр Мөнир Рамазановның «Без монголлар да һәм болгарлар да түгел, ә чын татарлар!» («Мы не монголы и не болгары, а настоящие татары!») дип исемләнгән җыентыгын укучыларга тәкъдим итү кичәсе узды.**



Озак еллар дәвамында милләтебезнең үткәнен җентекләп өйрәнүче Мөнир Рамазанов иң әүвәл очрашуда катнашучыларны татарның тарих сәхифәләре белән кыскача гына таныштырып үтте.

«Бу җыентыкны Мәскәү галиме Гали Еникеевның «По следам черной легенды» дип аталган китабына таянып әзерләдем. Әлеге китапта күрсәтелгәнчә, Бөек Идел Болгарстаны дәүләте территориясендә татарлар һәм чувашлар яшәгән, ә болгарлар бердә бөтенләй булмаган. Кубрат ханның улы бу якларга килеп урнашкан чорда Урта Идел буе җирләрендә мишәр-татар халкы көн күргән. Алтын Урда дәүләте башлыгы Чыңгыз хан ифрат та көчле, акыллы, гадел җитәкче буларак, барлык татарларны да бергә җыйган, үз тирәсенә туплаган. Ул Кытайны басып алып, 150 ел буе аның белән идарә иткән. Чыңгыз ханның оныгы Батый хан килгәндә безнең Болгар шәһәре җимерелгән була инде»,- дип сөйләде Мөнир Җиһанша улы.

Ислам дине булмаса, Идел Болгарстанында болгар дигән халык барлыкка килер идеме икән? Болгарлар бит алар күчеп килгән VIII-IX гасырлар чорында артык күп булмаган. Алар мәдәният, хәрби яктан көчле булганнар. Иделгә килгәч, көч белән түгел, ә белем, мәдәният белән тирә-юньдәге халыкларны берләштерә алган. Болгарлардан башка анда барсиллар, суварлар, бәрәнҗәрләр, искирләр булган, һәм бу төрки халыклар берләшкән. Шул ук вакытта, марилар, удмуртлар, мордвалар, дөресрәге, аларның борынгы бабалары да Болгар составына керә. Аларны берләштерә торган нигез - Ислам. Хәзер динебезне ихтирам итә башладык. Безне, бер караганда - архаика, урта гасырлар калдыгы формасында гына кабул итеп карарга була. Әмма Ислам булмаса, безнең татар күптән әллә нинди төркемнәргә бүленеп беткән булыр иде. Ул киләчәктә дә шулай булачак.

**Фәяз ХУҖИН, тарих фәннәре докторы, профессор, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе.**

Өлкә татар автономиясе рәисе Рамис Сафин танылган табиб, язучы, туган якны өйрәнүче һәм җәмәгать эшлеклесе Мөнир Рамазановның иҗади һәм фәнни хезмәтенә уңай бәя биреп, татар милләте тарихының бүгенге көндә дә бәхәсле мәсьәлә булып калуын ассызыклады. Казан галимнәре бу проблема буенча һаман да әле уртак фикергә килә алмыйлар, диде ул. Мохтарият җитәкчесе Мөнир әфәндегә күренекле тарихчы Камил Аблязовның «Историческая судьба татар» дип исемләнгән китабын да бүләк итте. Ә Сембер шагыйрәсе, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы Иделбикә «Мы не монголы и не болгары, а настоящие татары!» җыентыгын татар теленә тәрҗемә итеп, өлкә мәктәпләре һәм китапханәләренә таратырга тәкъдим итте. Мөнир дустыбыз ислам динен пропагандалау буенча да зур хезмәт башкара, аның берничә ел элек дөнья күргән «Веруйте!» җыентыгын хәзер дә әле зур кызыксыну белән укыйм, диде шагыйрә. Татар автономиясенең язучылар белән эшләү буенча бүлек җитәкчесе, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы Шәфикъ Иматдинов, Чардаклы районы Үрән авылыннан шагыйрь һәм краевед Фазылҗан Алиуллов та Мөнир әфәндене хезмәтен югары бәяләделәр. Бу китапның татарча вариантын «Өмет»ебез битләрендә бастырырга кирәк, укучылар татар тарихы белән танышсыннар, диде Фазылҗан ага. Ә шәһәребезнең Үзәк Җәмигъ мәчете мәхәлләсе вәкиле Варис Равилов һәм «Туган тел» мәгърифәтчелек оешмасы рәисе Рифат Бульхин, әлеге җыентык халкыбыз арасында аңлашылмаучанлык, ягъни фетнә китереп чыгармасмы соң, дип шикләнүләрен белдерделәр. Халкыбызның үткәнен краеведлар түгел, ә фәнни



гыйлемнәре булган галимнәр, дәрәҗәле тарихчылар өйрәнергә тиеш, диде Варис Равилов.

Соңгы елларда татар тарихы белән җитди рәвештә кызыксынучы тагын бер милләттәшебез - өлкә татар милли-мәдәни автономиясе рәисе урынбасары Рифгать Ахмедулловның чыгышын да зур игътибар белән тыңладылар.

«1944 елда, ягъни Бөек Ватан сугышы барган чорда КПСС Үзәк Комитеты Политбюросы «татарлар» дигән атаманы «болгарлар» дигән атамага алмаштыру турында карар чыгара. Чынлыкта исә болгар милләте дә, болгар теле дә булмаган һәм хәзер дә алар юк. Тарихи чыганакларга караганда, Шәһри Болгарда яшәүче татарлар кайвакыт үзләрен, без - болгарлар, дип атап йөрткәннәр. 2010 елда үткәрелгән халык санын исәпкә алу, ягъни перепись нәтиҗәләре буенча, Россия Федерациясендә барлыгы 1776 кеше болгар булып язылган, шуларның 147се безнең Ульяновск өлкәсендә яши»,- диде Р.Ахмедуллов.

Милли хәрәкәт ветераны Иркәм Хәйретдинов фикеренчә, Мөнир Рамазанов тарафыннан тарих фәннәре кандидатының гына көче җитәрлек зур хезмәт башкарылган. Әгәр бу җыентыкка Татарстан Фәннәр академиясенең Тарих институты галимнәре үзләренең рецензиясен язып бирсәләр, аның дәрәҗәсе тагын да арта төшәр иде, диде Иркәм ага. Ул, татар дигән сүз нинди мәгънәгә ия, дип соравын да җиткерде. Мөнир Рамазанов әйтүенчә, татар - ир-ат исеме ул, кайбер чыганакларда хәтта шундый фамилия дә очрый икән. Ә Кулаткы атамасы «кул атты», ягъни кечкенә җир дигән мәгънәне аңлата. Һәрхәлдә, туган якны өйрәнүче Хәмзә Абдулхак улы Аблязовның версиясе шундый, диде Мөнир Җиһанша улы.

17 нче милли китапханәнең татар бүлеге җитәкчесе Гөлфия Сәмигуллина алып барган кичәне «Хыял тамчылары» вокаль ансамбле солисты Айгөл Альметова үзенең моңлы җырлары белән бизәде.

Без - татарлар, телебез - татар теле, мөстәкыйль һәм төзек кагыйдәле камил тел. Бүтән телләрдән бер дә ким түгел ул.

**Каюм НАСЫЙРИ, галим, педагог, мәгърифәтче.**

**Исхак ХӘЛИМОВ.**